# *Гафур Колəхмəтов*



1881-1918

- 1881 елның 22 апрелендә (яңа стиль белән 5 майда) Пенза шәһәрендә сабын-шәм заводы хуҗасы гаиләсендә туа.

- 1897 елга кадәр алпавыт утарларында управляющий, бакчачы булып тора, соңыннан, Казанга килеп, Үтәмишевләрнең сабын заводына баш мастер булып урнаша.


- Гафур башта Пенза губернасының Түбән Ломов өязе Ятмис авылында мәдрәсә белеме ала, аннары Казан шәһәрендәге Укытучылар мәктәбендә укый.
- 1898—1902 Мәктәптә укыган елларында марксистик яшерен түгәрәккә йөреп, революцион әдәбият белән таныша, беренче татар большевигы Х. Ямашев, социал-демократ Г. Сәйфетдинов кебек революционерлар белән якыннан аралаша.

- 1918 елның 1 апрелендә озак еллар үпкә авыруыннан җәфаланган Гафур Коләхметов Пенза губернасындагы Краснослободск өяз больницасында вафат була.

Г. Коләхметов, язучы-драматург буларак, «Ике фикер» һәм «Яшь гомер» драмалары белән данлыклы.

Коләхметовның 1902—1912 еллар арасында иҗат иткән кайбер әдәби әсәрләре—дүрт пәрдәле «Әбүҗәһел» исемле тарихи һәм биш пәрдәле «Кем гаепле?» дип аталган драмалары, татар һөнәрчеләре тормышыннан алып язылган «Талак» исемле хикәясе, шигъри әсәрләре, вакытында матбугатта басылмау сәбәпле, сакланып калмаган. Ләкин «Ике фикер», «Яшь гомер» драмалары белән дә әдип татар әдәбияты тарихында иң мөхтәрәм урыннарның берсен били.
1909 елда аның «Тарих сәхифәләре» исемле өч кисәктән торган китабы басылып чыга. Ул шулай ук арифметика укыту алымнарына өйрәткән «Ысулы тәгълиме хисап» (1911) исемле методик кулланма китабы бастырып чыгара.









# Сез беләсезме?

1. Коләхмәтов Габделгафур Юныс улының псевдонимы ничек булган?

“Татарин театраль”

2. Г.Коләхмәтов портретын иҗат иткән рәссамнар?

Х.Якупов, Юлия Бейер, Н.Мифтахов

3. Г.Коләхмәтовның әдәби образын нинди романда табып була?

Кави Нәҗминең “Язгы җилләр”

4. Ничәнче елларда драматург “”Һәр хезмәтче (эшче) ни нәрсә белергә һәм ни нәрсә исендә тотарга тиешле” исемле шактый зур күләмле әсәрне русчадан татарчага тәрҗемә итә.

1904 – 1905 нче

5. Г.Коләхмәтовның гомуми тарих буенча тикшеренү буларак та, дәреслек-кулланма буларак та кулланылган хезмәте “Тарих сәхифәләре” дип атала. Ул ничә кисәктән тора

Өч

6. 1911 елның сентябрендә Казандагы нинди мәдрәсә каршында оештырылган рус классларына укытучы һәм мөдир булып күчә?

«Касыймия»

7. Иҗтимагый-сәяси карашлары ягыннан ул кем?

социал-демократ

8. Г.Коләхмәтов аеруча тыгыз аралашкан гаилә, шәхес. Г. Гобәйдуллин

9. Г.Коләхмәтовны замандашларыннан аерып куйган эшчәнлек төре.

марксистик әдәбиятны тәрҗемә итү

10. Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул эшләгән уку йорты.

Пороховой рус - татар училищесы

11. 1912-1916 еллар аралыгында кайда укыта?

“Касыймия” каршындагы рус теле сыйныфы

12. Г.Коләхмәтов мирасында кайсы иҗат агымы өстенлек итә?

Тәнкыйди реализм

13. Г.Коләхмәтов татар әдәбиятына нинди яңалык алып килә?

яңа тема, яңа геройлар алып килә

14. Г.Коләхмәтов бюстын кем эшләгән?

Ю.П.Бейер